**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТУБЫЛГЫТАУСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Ул.Молодежная, д.73,
с. Тубылгы тау,423181

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ТУБЫЛГЫ ТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Яшьләр урамы, 73
Тубылгы Тау авылы,423181

тел.: (8-84348) 3-82-58, факс: (8-84348) 3-82-44, Tub.Nsm@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2023 нче елнын 19 мае № 15

Хуҗасыз хайваннарны кайтару тыелган урыннарны билгеләү һәм хуҗасыз хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына турында карар кабул итәргә вәкаләтле затлар исемлеге турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Хайваннар белән җаваплы мөгамәлә итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 269-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Тубылгытау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны кайтару тыела торган түбәндәге урыннарны билгеләргә:

-ФАП территориясе;
-мәктәп һәм балалар бакчасы территориясе;
-авыл мәдәният йорты территориясе;
-парк территориясе;
-балалар уен һәм спорт мәйданчыгы территориясе;
-мәчет территориясе;
- кибет территориясе;
-зиратлар территориясе;
-Бөек Ватан сугышы елларында һәлак булган мемориаль комплекс территориясе.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге башлыгы Исмәгыйлев Фәнил Фәрит улын хуҗасыз хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итәргә вәкаләтле зат итеп билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: http://novosheshminsk.tatarstan.ru урнаштырырга, шулай ук Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Тубылгы Тау авылы, Яшьләр урамы, 73 нче йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Тубылгы Тау авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф. Исмәгыйлев